**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге составына керүче Татар Буасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

**19 ноябрь 2020ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Татар Буасы авылында юлларны төзекләндерүгә, зиратны төзекләндерүгә (хуҗалык корылмасын реконструкцияләү һәм инвентарь сатып алу), социаль билгеләнештәге объектларны төзекләндерүгә, кышкы чорда юлларны карап тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2020 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучы 494 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 293 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 278 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 15 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге составына керүче Татар Буасы авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Татар Буасы авылында юлларны төзекләндерүгә, зиратны төзекләндерүгә (хуҗалык корылмасын реконструкцияләү һәм инвентарь сатып алу), социаль билгеләнештәге объектларны төзекләндерүгә, кышкы чорда юлларны карап тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татар Буасы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ Р.Ф. Йосыпов.

Татар Буасы авыл җирлеге
башлыгы __________ Р.Ф. Йосыпов.